**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ИСКЕ ИСАКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**КЫРЫК ИКЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 5**

Иске Исаково авылы «20» май 2019г

**Иске Исаково авыл җирлеге Советының**
**2019 елның 14 февралендә булып узган**
**XLI сессиясендә кабул ителгән**
**“Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы**
**“Иске Исаково авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә**
**гавами тыңлаулар (җәмәгать тикшерүе)**
**оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы**
**Нигезләмәне раслау хакында”гы 5нче карарга**
**үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Иске Исаково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

**Иске Исаково авыл җирлеге Советы**
**КАРАР БИРДЕ:**

Иске Исаково авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендә булып узган XXXXV сессиясендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Иске Исаково авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать тикшерүе) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы Нигезләмәне раслау хакында”гы 4нче карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 4нче бүлектә:

*- 4нче пунктны яңа басмада бәян итәргә:*

«4. Гавами тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районы Иске Исаково авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районы “Иске Исаково авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (“Иске Исаково авыл

җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла.

Халык, Бөгелмә муниципаль районы Иске Исаково авыл җирлеге Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Иске Исаково авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә “Иске Исаково авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (“Иске Исаково авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла торганы “Иске Исаково авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Иске Исаково авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Э.М.Каримова**